БОЛЬШЕМЕНГЕРСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘТНӘ МУНИЦИАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ МӘҢГӘР АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422008, Республика Татарстан, Атнинский район, с.Большой Менгер, ул.Советская, д.8, т.3-46-25

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» август 2025 ел №10

**Олы Мәңгәр авыл җирлеге территориясендә хуҗаларсыз хайваннарны кайтару тыелган урыннарны билгеләү һәм хуҗаларсыз хайваннарны элеккеге хуҗаларсыз яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итәргә вәкаләтле затлар исемлеге турында**

2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ "Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында", Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы территориясендә хуҗасыз хайваннар белән эш итү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында" 2019 елның 30 декабрендәге 1275 номерлы карары, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының "Олы Мәңгәр авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә муниципаль берәмлек территориясендә яшәүче хуҗаларсыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатларында Олы Мәңгәр авыл башкарма комитеты карар бирә:

1. Олы Мәңгәр авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыелган түбәндәге урыннарны билгеләргә: балалар уен һәм спорт мәйданчыклары, парклар, зиратлар, дини объектлар, мемориаль зоналар, мәгариф оешмаларына, сәламәтлек саклау оешмаларына, мәдәният һәм сәнгать объектларына янәшә урнашкан территорияләр, сәүдә объектларына янәшә урнашкан территорияләр.
2. Олы Мәңгәр авыл җирлеге территориясендә хуҗаларсыз хайваннарны элеккеге хуҗаларсыз яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итү вәкаләтләрен үз өстемдә калдырам.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында: http://atnya.tatarstan.ru. адресы буенча бастырырга.
4. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Олы Мәңгәр авыл җирлеге башлыгы: Ф.Ф.Филатова